**Күкшел авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

28.01.2022 № 2

Күкшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнвары 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Күкшел авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Күкшел авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнвары 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Күкшел авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 11 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 16 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 11 номерлы, 2021 елның 11 июнендәге 13 номерлы, 2021 елның 23 ноябрендәге 26номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы Р.Р.Хәмидуллин

Совет Кукшинского сельского поселения Кукморского муниципального района Республики Татарстан
ОГРН 1021607753298
ИНН 1623002022